
# Адымнар нык,   юллар имин булсын



ТР Кайбыч муниципаль районы мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына белем бирү учреждениесе Олыкайбыч балалар бакчасы “Миләшкәй”

Тәрбияче: Аухадшина Светлана Александровнаның “Юлда йөрү кагыйдәләре буенча методик эшкәртмәсе.”

2015 ел

# Таныш булыйк – мин Светофор!



- Өч күзле светофор, –
  Күз кыскалау бар эше.
  Аның һәрбер әйткәнен
  Аңлый зиһенле кеше.

- «Туктап тор!» – ди
  кызыл күз,
  «Сабыр бул!» – ди
  сары күз.
  «Әйдә, кузгал!» – ди
  яшел күз
  Юлны ача – шушы күз!

# Кайсыбыз иң кирәкле? әкият

- Борын-борын заманда, өч ут яшәгән ди: кызыл, сары, яшел. Бервакыт болар арасында аңлашылмаучанлык килеп чыга. Кайсысы иң кирәкле?
- **Кызыл**. Мин иң югарыда торам. Кешеләрне, машиналарны туктатам. Шуңа мин иң кирәкле.
- **Сары**. Юк,мин бит кызыл белән яшелне аерып торам, барын да куркынычсызлык турында кисәтәм, мин иң кирәклесе.
- **Яшел.** Сез берегез дә дөрес әйтмисез. Мин иң аста торсам да, барысы да мине күрүгә йөри башлыйлар. Шуңа да мин иң кирәклесе.

Алар бик озак бәхәсләшәләр. Бөтен җирдә шау-шу башлана, юл һәлакәтләре артканнан арта. Беркем дә нишләргә кирәклеген белми. Акыллы, зирәк балалар тылсымчыны эзләп табалар һәм ул утларны бергә җыя да әйтә: “ Барыгыз да кирәкле, шуңа күрә сез гел бергә булырга тиеш . Шул вакытта гына юлларда тәртип булачак!”- ди.



# Юлны теләсә кайдан чыгарга ярамый!!!

- Тукта әле,әй, малай,

Тапталасың түгелме?
Билгеләрне белмисең,
Үзең юлдан йөрисең.
Ярый әле каршыңа
Чыкмады бер машина.



Менә шушындый билге ул
Җәяүле чыгу өчен.
Хәтта юлга да сызганнар



# Транспорт төрләре белән танышу.




- Әгәр кеше авырый икән,
Күрсәтә ул ярдәмне.




Шырпы белән уйнама син,
Янып китүең мөмкин.

---




- Газ белән уйнама син,
Шаярма алай бер дә.




- Тап булсаң әгәр, шикле кешегә,
Кичекмәстән шалтырат син 0...(2) гә.




SETRA



8324
8324


2379




КАМАЗ





# “Велосипедта йөри беләсеңме

Их, сәлиттә килгән булсак,
Җилдерә идек юлда.
Күрәсеңме, рәхәтләнеп
Йөрергә була монда.





Юк, кечкенә дустым, ялгышасың,
Кызыл түгәрәк ул безгә
“Ярамый” дип кисәтә!



Әгәр зәңгәр төстә булса,
“ Яраганны” күрсәтә.



# ЮЛЛАРДА САК БУЛЫГЫ

- Юл аша чыга калсаң,
  Як-якка кара әле:
  Уңга да кара әле,
  Сулга да кара әле,
  Игътибарсыз, бер уйсыз
  Син юлда барма, яме!

  Юл аша чыга калсаң –
  Зебраны читләп үтмә.
  «Җәяүлеләр юлы» ул,
  Ялгышсаң – бәла көтә.

  Юл йөрү кагыйдәсен
  Һәрвакытта белеп йөр.
  Барысын белсәң, үтәсәң,
  Булырсың, шиксез, өлгер!

  Исән-имин барырсың
  Теләгән һәрбер җиргә.
  «Сабыр төбе – сары алтын»,
  Онытмагыз сез бер дә.

- Бәла – аяк астында, – дип,
  Әйткән безнең бабайлар.
  Юл йөргәндә, зинһар
  өчен,
  Сак булыгыз, малайлар?!



# Кулланылган әдәбият:


- 1.”Азбука дорожной науки” под редакцией Г. В.Мухаметзяновой.
Казань,1999
- 2.”Сабантуй” газетасының кушымталары “Хәерле юл”
- 3.Валеева Ф. Газеева А.”Юлда йөри беләсеңме?”
- 4.Гарипова Р.Давлетшина Н.”Юл йөрү кагыйдәләре”